**ГЛАВА**
**Кадыбашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кадыбаш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2024 Кадыбаш авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кадыбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Кадыбаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кадыбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2024 елның 14 ноябрь көнне 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кадыбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2024 елның 14 ноябрь көнне 14 сәгать 30 минутта билгеләргә.
3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүлүне гамәлгә ашырырга:

-1 нче этап: Кадыбаш авылының Гали ур., Касай ур., Клуб ур., Яшьләр ур. яшәүчеләре.

-2 нче этап: Кадыбаш авылының Тауасты ур., Совет ур. яшәүчеләре.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Кадыбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл

итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 600 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?”:

«1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

2. Су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган су җыю манараларының су белән тәэмин итү һәм су түгү системасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу; җирлекне су белән тәэмин итү (тирәнлек насосларын сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау, су алу колонкаларын ремонтлау) һәм су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка чыгымнар).

3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу һәм янгын сүндерү автомобилен карап тоту) янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү һәм башка чыгымнар;

4. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү);

5. Торак пункт территориясен ( үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү: Кадыбаш авылында дизель ягулыгы, дизель мае, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу; тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар).».

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадыбаш авылы, Клуб ур., 49 а йорты, авыл мәдәният йорты.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Интерне» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Х.Л.Закиров